**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«11» 12 2024 ел Яр Чаллы ш. № 5530

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Акчәчәк» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Акчәчәк» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Акчәчәк» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 20 октябрендәге 3525 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы К.Р. Нәҗмиев

Муниципаль район Башкарма комитетының 2024 елның «11» 12 5530 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Акчэчэк» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Кызыклы инглиз теле» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Могҗизалар үз кулларың белән» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Развивайка» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Акчэчэк» балалар бакчасы мөдире _______________ А.Н. Камалова

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары _______________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Акчэчэк» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Кызыклы инглиз теле»** - чит телне үзләштерүгә кызыксыну тәрбияләүгә, гармонияле шәхес формалаштыруга, психик процессларны, шулай ук танып белү һәм тел сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән; актив һәм пассив сөйләм үсешенә, аңлы дәрәҗәдә дөрес тавыш әйтелешенә ярдәм итә.

Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (12 тәрбияләнүче).

2. **«Могҗизалар үз кулларың белән»**- иҗади сәләтләрне үстерүгә юнәлтелгән, баланың шәхес үсешенең барлык этапларын үз эченә алган процесс.

Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (10 тәрбияләнүче).

3. **«Развивайка»** - программа шәхесне, аның иҗади потенциалын, иҗади сәләтләрен, балаларның әхлакый-эстетик үсешен үстерүгә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (12 тәрбияләнүче).

ТР Тукай муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем
бирү учреждениесе - «Акчэчэк»
балалар бакчасы мөдире ____________ А.Н. Камалова

ДЕТСКИЙ САД "АКЧЭЧЭК"
ИНН 1639019889